# Сабантуй

Любимейший праздник татарского народа Сабантуй - одновременно древний и новый, праздник труда, в котором сливаются воедино красивые обычаи народа, его песни, пляски,обряды.

Название праздника происходит от тюркских слов: сабан - плуг и туй - праздник. Раньше Сабантуй праздновали в честь начала весенних полевых работ (в конце апреля), теперь же - в честь их окончания (в июне).

Этот древний праздник еще в 921 году описал в своих трудах знаменитый исследователь Ибн Фадлан, прибывший в Булгары послом из Багдада.

В старину празднование Сабантуя было большим событием, и к нему долго готовились. Всю зиму девушки, молодые женщины готовили подарки – ткали, шили, вышивали. Весной, перед началом праздника, молодые джигиты собирали по деревне подарки для будущих победителей в состязаниях и народных играх: вышитые платки и полотенца, куски ситца, рубашки, куриные яйца. Самым почетным подарком считалось вышитое национальным узором полотенце. Сбор подарков обычно сопровождался веселыми песнями, шутками, прибаутками. Подарки привязывали к длинному шесту, иногда джигиты обвязывали себя собранными полотенцами и не снимали их до конца церемонии. Аксакалы, своего рода совет Сабантуя, назначали жюри для награждения победителей, следили за порядком во время состязаний. Кульминацией праздника был майдан - состязания в беге, прыжках, национальной борьбе - керэш, и, конечно, конные скачки.

Постепенно Сабантуй сделался праздником всеобщим и межнациональным – сегодня он отмечается в селах, поселках, районах, городах, столице Татарстана, Москве, Санкт-Петербурге и во многих других регионах страны, а также в разных уголках мира, где проживают татары.

В настоящее время Сабантуй приобрел статус государственного праздника: издаются указы и постановления о подготовке, сроках и местах проведения, назначаются оргкомитеты из руководителей самого высокого ранга на каждом уровне (село, поселок, район, город, республика), определяются источники финансирования. Старинный праздник постепенно дополняется современными традициями, однако основные черты торжества сохраняются, переходя из века в век.

В Республике Татарстан Сабантуй проходит, как правило, в июне, в три этапа. В первую субботу по окончании весеннего сева праздник проводится в селах и деревнях республики, через неделю - в крупных городах Татарстана, а еще через неделю в столице республики г.Казани проходит главный Сабантуй. Во всех административных районах города организуются майданы для проведения состязаний, площадки для выступления мастеров культуры и искусств Татарстана, народные гулянья. На центральном ипподроме города проводятся скачки.

Во время своего визита в Казань в июне 2003 года Генеральный директор ЮНЕСКО К.Мацуура поддержал инициативу по выдвижению татарского национального праздника Сабантуй, являющего собой живую традицию и пользующегося искренней любовью народа, в число претендентов на включение в Список шедевров устного и нематериального наследия ЮНЕСКО.

С 2001 года в различных городах России проводится Федеральный Сабантуй.

# Сабантуй.

Татар халкының сагынып көтеп алынган Сабантуй бәйрәме борынгы бәйрәм, халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, җырлары һәм биюләре бергә кушылган хезмәт бәйрәме.

Бәйрәм атамасы борынгы төрки “сабан” һәм “туй” сүзләреннән килеп чыккан. Элегрәк Сабантуй карлар эреп беткәч, язгы кыр эшләренә 2-3 атна кала үткәрелгән, хәзер аны кыр эшләре тәмамлаганнан соң бәйрәм итәләр.

Сабантуй тамырлары белән ерак гасырларга барып тоташа. Бу бәйрәм турында 921 нче елда ук Багдад хәлифеннән Болгарга илче булып килгән атаклы Ибн Фадлан үзенең бөтендөньяга танылган хезмәтләрендә язып калдырган.

Иске заманда Сабантуй бәйрәме зур вакыйга булып исәпләнгән һәм аны бәйрәм итүгә хәзерлек эшләре озак барган. Кыш буена хатын-кызларыбыз бәйрәмгә бүләк әзерләгән, теккән, чиккән. Яз җитү белән малайлар йомырка, ә егетләр сөлге җыйган. Милли бизәкләр белән чигелгән сөлге иң кадерле бүләк булып саналган. Сөлге җыю, гадәттә, җыр-бию, уен-көлке белән бергә алып барылган. Бүләкләр колга башына эленгән, ә кайчакта егетләр үзләрен урап бәйләп куя торган була. Үзенә күрә Сабантуй шурасы булып саналган аксакаллар, ярышлар вакытында тәртип саклаган һәм җиңүчеләрне бүләкләү өчен жюри әгъзаларын билгеләгән. Бәйрәмнең кульминациясе - мәйдан. Биредә йөгерү, сикерү, милли көрәш буенча ярышлар, ат чабышлары үткәрелгән.

Акрынлап Сабантуй гомуми һәм милләтара бәйрәмгә әйләнә бара. Бүген аны Татарстан авылларында, поселокларында, районнарында, шәһәрләрендә генә түгел Мәскәүдә дә, Санкт-Петербургта да һәм татар диаспоралары яшәгән Россиянең һәм дөньяның башка төбәкләрендә дә бәйрәм итәләр.

Хәзерге вакытта Сабан туена дәүләт бәйрәме дәрәҗәсе бирелде. Аңа хәзерләнү һәм бәйрәм итү буенча указлар, карарлар чыгарыла, бәйрәмне финанслау чыганаклары билгеләнә.

Борынгы Сабантуй бәйрәме акрынлап матур, заманча традицияләр белән тулыландырыла. Шулай да бәйрәмебезнең асылы гасырдан-гасырга күчеп, сакланып килә. Татарстан Республикасында Сабантуй бәйрәме июнь аенда, гадәттә 3 этапта үткәрелә. Язгы кыр эшләре тәмамлануны башта авыл халкы бәйрәм итә, аннан Сабантуй республикабызның зур шәһәрләрендә гөрләп уза. Соңгы этап башкалабыз – Казанда, шәһәребезнең барлык административ районарында үткәрелә. Зур-зур мәйданнарда спортчылар, сәнгать осталары ярыша. Үзәк ипподромда ат чабышлары үткәрелә. Халык күңел ача.

2003 елда үзенең Татарстанга визиты вакытында ЮНЕСКО Генераль директоры К.Мацуура Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиевнең татар халкының милли «Сабантуй» бәйрәмен ЮНЕСКОның кешелек мирасы сөйләмә һәм матди булмаган шедеврлары исемлегенә кертергә кирәклеге турындагы тәкъдимен хуплап чыкты.

## Весёлый праздник Сабантуй.

4 июня в детском саду провели Сабантуй. Это один из самых любимых летних праздников детей. Сабантуй расширяет представления детей о татарском народном празднике. Он прививает любовь и уважение к национальным праздникам разных народов, воспитывает дружеские взаимоотношения между людьми, формирует доброжелательные отношения к сверстникам разных национальностей. Сабантуй доставляет детям радость, воспитывает патриотические чувства к родному краю и толерантное отношение к другим народам.

На этом празднике дети познакомились с традициями, обычаями, народными играми татарского народа. Дети были в восторге от проведенного мероприятия.

Сабантуй – төрле милләт кешеләрен берләштерүче электән үк сакланып килгән чын милли бәйрәмебез. Ул – хезмәт һәм дуслык бәйрәме.

Милли бәйрәмнәрне уздыру безнең балалар бакчасында матур традиция. Мондый чаралар уздыру, балаларны төрле яклап үстерә. Беренчедән, алар татар халкының милли бәйрәме белән яңадан танышалар, гореф-гадәтләрне өйрәнәләр. Икенче яктан, саф һавада йөгереп, уйнап сәламәтлекләрен ныгыталар.

Бакчадагы бәйрәм матур шигырьләр, күмәк җырлар белән аралашып барды. Балалар барлык уеннарда да теләп катнаштылар. Аларның хис-кичерешләрен әйтеп бетергесез.

Сабантуй бәйрәме күңелләрне күтәрә, ел буена җитәрлек шаян көч бирә.